**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Якты Күл авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

20.07.2020 ел. № 168

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге Уставына таянып, Якты Күл авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне, әлеге карарга кушымта нигезендә редакциядә бәян итеп, расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 21 сентябрендәге 116 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтындагы «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Якты Күл авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **З. З. Мөхтәров**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлеге
Советының 2020 елның
20 июлендәге 168 номерлы
карарына кушымталар

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының **Якты Күл** авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының **Якты Күл** авыл җирлеге Уставына таянып эшләнгән.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия торак пункт халкы, даими яисә нигездә аның территориясендә яшәүчеләр, катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыяри һәм ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнашалар, һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены турыдан-туры халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатында үткәрелә.

1.6. Торак пунктта, әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгының бер үк вакытта бергә җыенда катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап уздырыла.

## Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелә ала:

- аның составына керә торган күрсәтелгән торак пунктның, җирлекнең (муниципаль районның) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, әгәр дә торак пункт чикләрен үзгәртү башка җирлек (муниципаль район) территориясенә күчерүгә китерсә;
- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гражданнар җыены гамәлгә ашыра торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча;
- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия җирлек халкы 100дән

артык кеше булса, җирлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турында мәсьәлә буенча

- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында мәсьәлә буенча;

- җирлек составына кергән торак пунктта, шәһәр эчендәге районда, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориядә, муниципаль округта, шәһәр округында, яисә муниципаль район чикләрендәге авылара территориядә урнашкан җирлектә, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

- авылара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатыннан, әгәр сайлау хокукына ия аның халкы саны 300 кешедән дә артмаса, яңа төзелгән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

- авыл җирлегенең тыгызлыгы түбән яисә барып җитү мөмкинлеге авыр булган җирдә урнашкан, әгәр авыл җирлеге халкын саны 100 кешедән артмаса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

- авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

- авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Җыенны үткәрү җирлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар җирлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыенын үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү инициативасы белән чыга алалар:

- җирлек башлыгы;

-гражданнар җыенында катнашу хокукына ия булган 10 кешедән дә ким булмаган, сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүче гражданнар (ягъни Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән 18 яшькә җиткән даими яки нигездә яшәүчеләр, шулай ук чит ил гражданнары, торак пункт территориясендә даими яки нигездә яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия булган гражданнар).

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имза битләре (1нче кушымта) яки гражданнар җыенын үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында карар кабул ителгән инициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш. Беркетмәдә түбәндәге мәсьәләләр чагылыш табарга тиеш:

-гражданнар җыенына чыгарыла торган сораулар;
-гражданнар җыенын үткәрү өчен тәкъдим ителгән вакыт;
-гражданнар җыенын чакыру турында инициативаны хуплаучы һәр гражданның исеме, атасының исеме, туган көне; паспортның яисә аның документының сериясе һәм номеры; аның имзасы һәм имза кую датасы.

2.3. Җыен үткәрү инициативасын хуплап җыярга кирәк булган имзалар саны торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия даими яки нигездә яшәүче гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, әмма 10нан да ким имза була алмый.

2.4. Имза кәгазьләре имзалар җыюны тормышка ашыручы зат тарафыннан, раслату датасын, кул куючының исем-фамилиясен, атасының исемен, туган датасын, паспорт номерын һәм сериясен, яшәү урыны адресларын күрсәтеп, авыл җирлеге башлыгына җибәрелә.

**Халык җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе**

2.5. Инициативалы төркем тарафыннан үткәрелә торган гражданнар җыены муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары (2нче кушымта), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы буенча – муниципаль берәмлек башлыгы карары (3нче кушымта) белән барлык кирәкле документлар кергән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, аның максатка ярашлы булмавын дәлилләп, җыенны үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә аңа күп яклы аңлатма бирү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп формалаштырылырга тиеш, ягъни аңа анык бер төрле генә җавап бирергә мөмкин булырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү турында карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) тәртибе, аны күчерү муниципаль берәмлек тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә бастырып чыгарыла (игълан ителә).

Муниципаль берәмлек башлыгы карарында яисә гражданнар җыенын уздыру турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы - муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында белешмәләр;

2.9. Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе (башкарма-боеру органы) муниципаль берәмлек башлыгы карары яисә муниципаль берәмлек вәкиллекле органының гражданнар җыенын үткәрү турындагы карары нигезендә сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең исемлекләрен төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында халыкка хәбәр итә (4нче кушымта).

Муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы гражданнар җыенын үткәрү өчен биналар бирергә тиеш.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү һәм гражданнар җыенын уздыру датасын билгеләү территориаль, вакыт билгеләре буенча, шулай ук башка очракларда мөмкин.

2.9.2. Җыен этаплап үткәрелгән очракта, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (№5, 6 кушымта). 5нче кушымта гражданнарның инициатив төркем инициативасы буенча этаплап җыен үткәрү очрагында кулланыла, 6 кушымта - муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы белән гражданнар җыенын этаплап уздыру очрагында.

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыены үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә. Гражданнар җыенын (этапларны) билгеләү турында карар, гражданнар җыенын (этапларны) үткәрү вакыты һәм урыны, гражданнар җыенын үткәрү датасына (гражданнар җыены этапларына) 10 көннән дә соңга калмыйча, мәҗбүри бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Гражданнар җыенын этаплап үткәрү вакыты һәм урыны бер карарда яки җыенны билгеләү турында карарда күрсәтелә.

2.9.4. Халык җыенын этаплап үткәргән очракта, җыеннар этаплап гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Гражданнар җыены этаплары күчерелгән очракта, гражданнар җыенын күчерү турында карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча һәм закон нигезендә җыен үткәрелергә тиешле айлык чорны исәпкә алып кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Гражданнар җыенының һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча әлеге нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгәнчә муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турында нигезләмә буенча гражданнар җыенын уздыру датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын күчерү турында карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Халык җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия затларны теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан вәкаләтләр бирелгән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы, паспортының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга шулай ук хәлиткеч тавыш хокукыннан башка җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнар, оешма, предприятие җитәкчеләре, җыелышта тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлеге белән бәйле булса, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә кертелә..

3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче әлеге муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм җыенда катнашуга кертелергә мөмкин.

3.4. Гражданның шәхесен раслаучы документ (яки аларның булмавы) язмалардагы төгәлсезлекне раслаучы документ булып хезмәт итә (Россия Федерациясе гражданы паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт һ. б.)

3.5. Гражданнар җыены сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы була. Кворум булмаганда, гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү билгеләнгән көннән ун көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

3.6. Гражданнарның җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыенының аерым этапларында гражданнарның күпмесе килүгә карамастан, җыен хокуклы дип санала, барлык уздырылган этаплар нәтиҗәләре буенча тавышлар бергә санала, ягъни җыен бер булып исәпләнә.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яки яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.8. Яшерен тавыш бирү уздырганда гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (7нче кушымта).

3.9. Халык җыенында муниципаль берәмлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүчегә кандидатураларны гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.10. Гражданнар җыены секретарьне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән дә ким була алмый.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) җыенга килгән торак пунктта яшәүчеләрнең теркәлү дөреслеген тикшерә, кирәк булганда аларның гражданнар җыены эшендә катнашу хокукын;

2) гражданнар җыенының кворумын билгели (гражданнар җыены этапларын уздырудан тыш);

3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

4) тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый (җыен этапларын үткәрүдән тыш);

5) тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзи (халык җыены нәтиҗәләре буенча);

6) рәислек итүчегә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материалларны тапшыра (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге).

3.11. Җыенның көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә халык җыены инициаторлары тарафыннан күтәрелгән мәсьәләләр мәҗбүри рәвештә кертелә. Әлеге мәсьәләләр беренче чиратта карала. Гражданнар җыены көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турында карар,

әгәр аның өчен җыенда катнашучы гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.12. Этаплап халык җыенын уздыру вакытында шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.13. Гражданнарның этаплап үткәрелә торган җыенында тавыш бирү ачык яки ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында карар гражданнар җыены этабында кабул ителә.

3.14. Гражданнарның этаплы җыенын уздырганда, гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясе санынннан гражданнар җыенын уздыруның һәр этабында кворум һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк санау комиссиясенең берәр әгъзасы сайлана.

3.15. Җыенда рәислек итүче тарафыннан гражданнар җыены ачыла. Җыенда рәислек итүче гражданнар җыенын уздыруны оештыра, тәртип урнаштыра, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, билгеләнгән тавыш бирү тәртибен тәэмин итә.

3.16. Гражданнар җыенында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенын уздыру датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнарның саны, анда катнашучыларның саны, көн тәртибе, чыгымнарның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (8нче кушымта).

3.17. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда гражданнар җыенының һәр этабында беркетмәләр (9,10нчы кушымталар) алып барыла, алар алга таба гражданнар җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә (11нче кушымта), шулай ук хисап комиссиясе беркетмәләре дә (12,13нче кушымталар), алар шулай ук гражданнар җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә (14нче беркетмә).

3.18. Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе гражданнар җыены этапларын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында белешмәләрне, көн тәртибен, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында күрсәткечләрне, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре турында белешмәләрне үз эченә ала. Йомгаклау беркетмәсе авыл җирлеге башлыгы кул куйган халык җыены карарын рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү )өчен нигез булып тора.

3.19. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыенның секретаре имза сала һәм ул муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучыларның исемлеге теркәп бирелә.

3.20. Халык җыены нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә халык җыенын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, җыенның көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, халык җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыен үткәрү өчен билгеләнгән территориядә

яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, ӘЙЕ, ЮК дип бирелгән тавышларның гомуми саны.

3.21. Йомгаклау беркетмәсенә хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары имза сала һәм ул муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Халык җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен сайлау хокукына ия булган гражданнарның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары җирлек уставында билгеләнгән үзара вәкаләтләр бүлешү нигезендә гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыеннарда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә яки суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм муниципаль хокукый актларга куелган таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең турыдан-туры белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый актны кабул итү (чыгару) таләп ителсә, җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи заты, гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

## Халык җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм аларны нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яки җирле үзидарә органнарының раславы кирәк түгел

4.8. Җыенда кабул ителгән карарны үтәмәүчеләр закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
1нче кушымта

## КУЛТАМГА КӘГАЗЕ

Без, түбәндә кул куючылар, ____________________________Зәй муниципаль районы ________________ авыл җирлегенең____________________авылында түбәндәге сорауларны карау очен ______________________________________________гражданнар җыены үткәру инициативасын хуплыйбыз.

| №№ п/п | Фамилиясе исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспорт (аны алыштыра торган документ ның) сериясе, номеры | Кул кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |
| … | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Култамга кәгазен раслыйм ______________________________________________________
(имза җыючы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне,
_______________________________________________________________________________
яшәү урыны, паспорт сериясе һәм номеры)

________________________ (имза һәм дата)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
2нче кушымта

<table>
<tr><td>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Светлоозерского сельского поселения Заинского муниципального района<br>индекс с. ул. дом телефон</td><td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы<br>индекс ___авылы___ ур. Йорт телефон</td></tr>
</table>

ОГРН_______ , ОКПО______ , ОКАТО_______,
ИНН/ КПП _____/______,ОКТМО ______

---

**КАРАР**

**_______ 2020 ел** **№ ____**

**Зәй муниципаль районының_____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, _____________авыл җирлеге Уставы нигезендә, _____________авыл җирлеге Советы

***КАРАР ИТТЕ:***

1. Зәй муниципаль районының _____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын керту һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның ________ 00 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 20__ елда ________торак пунктында теркәлгән, һәр балигъ гражданга_____сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, үзара салымнан азат ителгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан тыш, һәм аның түбәндә күрсәтелгән эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

"ӘЙЕ «ЮК»

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Бигеш авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соңгы ______ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

_____________ авыл җирлеге
Советы рәисе ФИА

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
3нче кушымта

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Светлоозерского селького поселения Заинского муниципального района**
индекс с. ул. дом телефон

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы**
индекс ___авылы ___ ур. Йорт телефон

ОГРН_______ , ОКПО______ , ОКАТО_______,
ИНН/ КПП _____/______,ОКТМО ______

---

**Татарстан Республикасы _____________ авыл җирлеге башлыгының**
**2020 елның_________ ___ номерлы карары**

**«Зәй муниципаль районының_____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 – ТРЗ номерлы Татарстан Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, _____________авыл җирлеге Уставы нигезендә, _____________авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районының _____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын керту һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның ________ 00 сәгатькә билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 20__ елда ________торак пунктында теркәлгән, һәр балигъ гражданга_____сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, үзара салымнан азат ителгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан тыш, һәм аның түбәндә күрсәтелгән эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

"ӘЙЕ «ЮК»

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Бигеш авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соңгы ______ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Якты Күл авыл җирлеге башлыгы ____________ ФИА

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
4нче кушымта

Зәй муниципаль районы ___________авыл җирлеге торак пунктларында теркәлгән сайлау хокукына ия гражданнарның
ИСЕМЛЕГЕ

«___» _________________ 2020 ел

| №№ пп | Фамилиясе исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшь тулганнарга туу датасы) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыены рәисе __________ ___________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены секретаре __________ _________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
5нче кушымта

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Светлоозерского сельского поселения Заинского муниципального района**
индекс с. ул. дом телефон

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Советы**
индекс ___авылы ___ ур. йорт телефон

ОГРН_______ , ОКПО______ , ОКАТО_______,
ИНН/ КПП _____/______,ОКТМО ______

**К А Р А Р**

**_______ 2020 ел** **№ ____**

**Зәй муниципаль районының_____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, _____________авыл җирлеге Уставы нигезендә, _____________авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районының _____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның ________ 00 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Зәй муниципаль районының _____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның ________ 00 сәгатькә билгеләргә.
3. Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең __________________________ торак пунктында яшәүчеләр исемлеген түбәндәге билгеләр буенча бүләргә:

___________________________________________________________________________

*(территориаль, вакыт яисә башка билгеләр)*

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 20__ елда ________торак пунктында теркәлгән, һәр балигъ гражданга_____сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, үзара салымнан азат ителгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан тыш, һәм аның түбәндә күрсәтелгән эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

"ӘЙЕ «ЮК»

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Бигеш авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соңгы ______ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Якты Күл авыл җирлеге
Советы рәисе ФИА

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
6нчы кушымта

| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **Глава Светлоозерского селького поселения Заинского муниципального района** | **Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге Башлыгы** |
| индекс с. ул. дом телефон | индекс ___авылы ___ ур. йорт телефон |

ОГРН_______ , ОКПО______ , ОКАТО_______,
ИНН/ КПП _____/______,ОКТМО ______

---

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге башлыгының 2020 елның_____________ _____ номерлы карары**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Зәй муниципаль районының _____________________ Якты Күл авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 – ТРЗ номерлы Татарстан Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, _____________авыл җирлеге Уставы нигезендә, _____________авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районының _____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның ________ 00 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Зәй муниципаль районының _____________авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның ________ 00 сәгатькә билгеләргә.
3. Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең __________________________ торак пунктында яшәүчеләр исемлеген түбәндәге билгеләр буенча бүләргә:

_____________________________________________________________________________

(территориаль, вакыт яисә башка билгеләр)

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 20__ елда ________торак пунктында теркәлгән, һәр балигъ гражданга_____сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, үзара салымнан азат ителгән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан тыш, һәм аның түбәндә күрсәтелгән эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

"ӘЙЕ «ЮК»

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Бигеш авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соңгы ______ көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Якты Күл авыл җирлеге башлыгы ФИА

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
7нче кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирү өчен

**БЮЛЛЕТЕНЬ**

| | | |
|---|---|---|
| Яшерен тавыш бирүгә куелган сорауның эчтәлеге | «ӘЙЕ» | ☐ |
| | «ЮК» | ☐ |

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
8нче кушымта

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

______________________________________________________________
(торак пунктның исеме)

«___» _____________ 2020 ел 00 сәгать 00 минут № _____

Катнашты ___________________________________________________________ кеше.
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнарның саны, катнашучыларның саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче _____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Гражданнар җыены секретаре _____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

## КӨН ТӘРТИБЕ:

1.

2.

## ҖЫЕННЫҢ РӘИСЕ САЙЛАНА:

*1. Ф.И.А. – вазыйфасы*
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## ҖЫЕННЫҢ СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:

**Рәислек итүче:** җыенның секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?
Җыен секретаре итеп________________(ФИА, вазыйфасы) сайлау тәкъдиме дә бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» - ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

**Рәислек итүче**: халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен санау, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп________________(ФИА) һәм хисап комиссиясе әгъзалары итеп түбәндәгеләрне сайлау тәкъдиме дә бар:

*1. Ф.И.А.*
*2. Ф.И.А.*

һ.б.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## Көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү тәртибе билгеләнә:

**Рәислек итүче:** көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү формасын ачыклау мөһим. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында тәкъдим яңгыратыла.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШЛӘҮ:

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
_____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. _____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)
һәм башкалар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче сорау буенча тыңладылар:**
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)
һәм башкалар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Карар иттеләр:** (карарның эчтәлеге)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче ________ ________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены секретаре ________ ________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
9нчы кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 2020 ел 00 сәгать 00 минут № __1___

Катнаштылар _______________________________________________________ чел.
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнарның саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче _________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены секретаре __________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

**ҖЫЕННЫҢ РӘИСЕ САЙЛАНА:**

1. Ф.И.А. – вазыйфасы
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:**

Рәислек итүче: җыенның секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?
Җыен секретаре итеп________________(ФИА, вазыйфасы) сайлау тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:**

**Рәислек итүче:** халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен санау, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп________________(ФИА) һәм хисап комиссиясе әгъзалары итеп түбәндәгеләрне сайлау тәкъдиме дә бар:
1. Ф.И.А.
2. Ф.И.А.
һ.б.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ МӘСЬӘЛӘСЕ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:**

**Рәислек итүче:** көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү формасын ачыклау мөһим. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында тәкъдим яңгыратыла.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

**КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШЛӘҮ:**

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)
һәм башкалар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)
һәм башкалар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Карар иттеләр: (карарның эчтәлеге)**
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе, гражданнар җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча, Якты Күл авыл җирлеге Уставы нигезендә, рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка җиткереләчәк).**

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены секретаре _________ _________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
10нчы кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ (һ.б.)**

______________________________________________________________

(торак пунктның исеме)

«___» ____________ 2020 ел 00 сәгать 00 минут № __2___

**Катнаштылар** _____________________________________________________ кеше.
(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны,сайлау хокукына ия гражданнарның саны, катнашучлар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче __________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Гражданнар җыены секретаре ___________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме)

## КӨН ТӘРТИБЕ:

1.

2.

## ҖЫЕННЫҢ РӘИСЕ САЙЛАНА:

1. Ф.И.А. – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## ҖЫЕННЫҢ СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:

**Рәислек итүче:** җыенның секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак? Җыен секретаре итеп________________(ФИА, вазыйфасы) сайлау тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

**Рәислек итүче:** халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен санау, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп________________(ФИА) һәм хисап комиссиясе әгъзалары итеп түбәндәгеләрне сайлау тәкъдиме дә бар:
1. Ф.И.А.
2. Ф.И.А.
һ.б.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕ МӘСЬӘЛӘСЕ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮ ТӘРТИБЕ БИЛГЕЛӘНӘ:

Рәислек итүче: көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү формасын ачыклау мөһим. Тавыш бирү ачык яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирү формасы турында тәкъдим яңгыратыла.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШЛӘҮ:

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:**

________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

һәм башкалар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар:**
________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (теркәлә)
һәм башкалар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)…

**Карар иттеләр**: (карарның эчтәлеге)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Әйе» ____ кеше
«Юк» ____ кеше

Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Рәислек итүче: йомгаклау карарының нәтиҗәсе, гражданнар җыенының үткәрелгән этапларының тавышларын санау нәтиҗәләре буенча, Якты Күл авыл җирлеге Уставы нигезендә, рәсми рәвештә басылып чыгачак (халыкка җиткереләчәк).**

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ __________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Гражданнар җыены секретаре _________ __________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Кул авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
11нче кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ҮТКӘРЕЛГӘН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ БЕРКЕТМӘСЕ**

___________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль районы торак пунктының исеме)

«______» _________ 2020 ел 00 сәгать 00 минут № ____

2020 елның __ _______ 1нче номерлы беркетмә нигезендә беренче этапта (рәислек итүче ФИА), 2020 елның __ _______ 2нче номерлы беркетмә нигезендә икенче этапта (рәислек итүче ФИА) һ. б. этаплы халык җыеннары түбәндәге мәсьәлә (ләр) буенча уздырылды ____________________________________________________________

1. Тавыш бирү формасы күрсәтелгән (ачык, яисә ябык (яшерен) этаплар саны _______
2. Этаплап үткәрелгән гражданнар җыеннары беркетмәләре саны ______
3. Җыен үткәрү өчен билгеләнгән территориядә яшәүчеләр һәм җыенда катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны __________;
4. Сайлау хокукына ия гражданнарның гомуми саны _________ һәм гражданнар җыенында катнашучылар саны___________

**КАРАР ИТТЕ: (карарның эчтәлеге)**

- Җыен этапларында кертелгән сорауга (ларга) «Әйе» тавышларының гомуми саны _________;
- Җыен этапларында кертелгән сорауга (ларга) «Юк» тавышларының гомуми саны _________;

**КАРАР: кабул ителде (кабул ителмәде, сәбәбен күрсәтеп)**

Рәислек итүче (җирлек башлыгы): ______ ________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Секретарь: _________ ______________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
12нче кушымта

## Гражданнар җыенының икенче этабы буенча хисап комиссиясе беркетмәсе

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге составына керә торган ________________ торак пунктында тавыш бирү нәтиҗәләре

«_____» _______ 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге торак пунктының исеме

**Катнашалар:** хисап комиссиясе әгъзалары:
1. ФИА;
2. ФИА;
һәм башкалар.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия ______граждан катнаша (катнашты).

Гражданнар җыенының беренче этабы көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«________________________________________________________________________»

**Әйе__________тавыш**

**Юк________тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе ФИА
Хисап комиссиясе әгъзалары:

ФИА

ФИА

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
13нче кушымта

**Гражданнар җыенының икенче этабы буенча хисап комиссиясе беркетмәсе**

Татарстан Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге составына керә торган ________________ торак пунктында тавышларны санау нәтиҗәләре турында

«_____» _______ 2020 ел № 2
торак пунктның исеме
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге *торак пунктының исеме*

**Катнашалар:** хисап комиссиясе әгъзалары:
1. ФИА;
2. ФИА;
һәм башкалар.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия ________граждан катнаша (катнашты).

Гражданнар җыенының икенче этабы көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«________________________________________________________________________»

**ӘЙЕ__________тавыш**

**ЮК_________тавыш**

Хисап комиссиясе рәисе: ФИА
Хисап комиссиясе әгзалары:

ФИА
ФИА

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә
14нче кушымта

**ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең_______________ авылында халык җыенының беренче, икенче һ. б. этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирү йомгаклары турында**

«___» ____________ 2020 ел ______________________________________________
(торак пунктның исеме)
Территориядә уздырылган гражданнар җыенының беренче, икенче (һ.б.) этапларының тавыш бирү йомгаклары ____________________________________________________
_____________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлекнең яисә аның өлешенең
_____________________________________________________________________________
территориясе исеме)
Гражданнар җыены этапларын уздыру датасы һәм вакыты: _____________ ____________ 2020 ел
Тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә гражданнар җыеннарында сорау (лар) буенча _________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

**Хисап комиссиясе билгеләде:**

1. Гражданнар җыенының уздырылган этаплары саны _______________________;
2. Гражданнар җыенының уздырылган этапларының хисап комиссиясенә тапшырылган беркетмәләре саны ____________________;
3. Җыен үткәрү өчен билгеләнгән һәм җыен эшендә катнашу хокукы булган территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны __________;
4. Җыенда катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________________;
5. Җыен этапларында кертелгән сораууга (ларга) **«Әйе»** тавышларының гомуми саны _________;
6. Җыен этапларында кертелгән сораууга (ларга) **«Юк»** тавышларының гомуми саны _________;

**Карар иттеләр:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы законның 25 статьясы 6 өлеше нигезендә _____________________________________________мәсьәләсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга, ____________________________ мәсьәләсе буенча җыенның карарын кабул ителгән дип санарга.

Хисап комиссиясе рәисе ______________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)
Хисап комиссиясе әгъзалары 1. __________________________ ________________
(фамилиясе, инициаллары) (имза)
2. __________________________

Беркетмә 2020 елның «___» _____________ төзелде.